Татарстан РеспубликасыӘлмәт муниципаль районы
РусАкташы авыл җирлеге башлыгы

КАРАРЫ

07 ноябрь 2019 ел N11

Әлмәт муниципаль районыРус Акташы
авыл җирлегенең Акташстанция сендә
гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе
буенча халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл җирлегенең Акташ станциясендә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын2019 елның 18 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2.Халыкҗыенычыгарылаторганмәсьәләнерасларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Рус Акташы авыл җирлегенең Акташ станциясетерриториясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге җыелган акчаларны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:Акташ станциясе юлларын норматив хәлгә китерү?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

3.Халык җыенын Татарстан РеспубликасыӘлмәт районы Акташ станциясенең конторабинасындаүткәрергә.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Рус Акташы авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны җыен үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Акташ станциясе контора бинасы территориясендә урнашканмахсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга(халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Рус-Акташы авылы җирлеге
башлыгы С.А. Белоногов